| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25 сентября 2017 г. № 5702

Башкарма комитетның 2016 елның 3 ноябрендәге 5793 номерлы карары белән расланган 2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының «2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 2016 елның 15 декабрендәге 13/5 номерлы карары, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2016 елның 3 ноябрендәге 5793 номерлы карары (Башкарма комитетның 2017 елның 10 мартындагы 1182 номерлы, 2017 елның 14 апрелендәге 2234 номерлы, 2017 елның 24 июлендәге 4318 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган 2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) I. «Халыкның аз керемле категорияләренә материаль ярдәм күрсәтү» бүлегендә:

- 1 пунктта:

«Башкаручылар» графасына «Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе» сүзләрен өстәргә;

«Финанслау чыганагын күрсәтеп, финанслау, 2017 ел (мең сум)» графасында «85,0» цифрларын «95,0» цифрларына алмаштырырга;

- «БАРЛЫГЫ» юлында:

«Индикаторларның зурлыгы 2017 ел кеше» графасында «85,0» цифрларын «95,0» цифрларына алмаштырырга;

2) II. «Бәйрәм һәм истәлекле даталарга багышланган чаралар оештыру һәм үткәрү» бүлегендә

- 5 пунктта:

«Индикаторларның зурлыгы 2017 ел кеше» графасында «158» цифрларын «411» цифрларына алмаштырырга;

«Финанслау чыганагын күрсәтеп, финанслау, 2017 ел (мең сум)» графасында «158» цифрларын «411» цифрларына алмаштырырга;

- «БАРЛЫГЫ» юлында:

«Индикаторларның зурлыгы 2017 ел кеше» графасында «1685» цифрларын «1938» цифрларына алмаштырырга;

«Финанслау чыганагын күрсәтеп, финанслау, 2017 ел (мең сум)» графасында «884,0» цифрларын «1137,0» цифрларына алмаштырырга;

3) IV. «Балалары булган аз керемле гаиләләргә социаль ярдәм чараларын тормышка ашыру» бүлегенең «Финанслау чыганагын күрсәтеп, финанслау, 2017 ел (мең сум)» графасында:

4 пунктта «400,0» цифрларын «137,0» цифрларына алмаштырырга;

«Барлыгы» юлында «1858,0» цифрларын «1595,0» цифрларына алмаштырырга

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин